КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 8 сентябрь г.Казань № 673

«Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, халыкның барлык катламнары өчен алардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган оешмаларга карата таләпләрне стандартлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына әлеге карар белән расланган «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын ведомство буйсынуындагы «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт мәгариф оешмаларына җиткерергә һәм аның таләпләре үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән расланган «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын муниципаль учреждениеләр күрсәтә торган тиешле муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү өчен куллануны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Төбәк әһәмиятендәге өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартлары турында» 2010 ел, 19 июль, 573 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 ел, 12 октябрь, 846 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартлары турында» 2010 ел, 19 июль, 573 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 29 ноябрь, 931 нче.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин